АЛЕКСЕЕВСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
АЛЕКСЕЕВСК
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.04.2019 Алексеевск ш.т.б. №241

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 2017 елның 10 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә дәүләт экология экспертизасы объектлары буенча җәмәгать фикер алышуларын үткәрү тәртибен кабул итү турында» 113 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 01.03.2010 елның 1 мартындагы 02-06-2019 номерлы проектын үтәү,шулай ук гамәлдәге законнарга, шул исәптән Россия Федерациясе Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2000 елның 16 маендагы 372 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясендә әйләнә-тирә мохиткә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең йогынтысын бәяләү турында Нигезләмәгә туры китерү максатларында

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 2017 елның 10 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә дәүләт экология экспертизасы объектлары буенча җәмәгать фикер алышуларын үткәрү тәртибен кабул итү турында» 113 номерлы карарына түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләр кертергә:

1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3.Йогынтыны бәяләү өч этапта үткәрелә:

- хәбәрнамә тапшыру;
- алдан бәяләү;
- әйләнә-тирәлеккә йогынтыны бәяләү үткәрүгә техник бирем төзү.

Беренче этап барышында заказ бирүче:

- хакимият органнарына ниятләнгән эшчәнлекнең гомуми тасвирламасын үз эченә алган төп документация әзерли һәм тапшыра; аны тормышка ашыру максатлары;

мөмкин булган альтернатива; аны тормышка ашыру шартлары тасвирламасы; гамәлдәге норматив документлар белән каралган башка мәгълүмат;

- җәмәгатьчелеккәРоссия Федерациясе Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2000 елның 16 маендагы «Россия Федерациясендә әйләнә-тирә мохиткә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең йогынтысын бәяләү турындаНигезләмәне раслау турында»372 номерлы боерыгы таләпләре нигезендә хәбәр итә.
- Россия Федерациясе Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2000 елның 16 маендагы «Россия Федерациясендә әйләнә-тирә мохиткә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең йогынтысын бәяләү турындаНигезләмәне раслау турында»372 номерлы боерыгындагындагы 3.2.2 пунктының төп нигезләмәләре буенча алдан бәя бирә;
- бәяләү процессында катнашучыларны билгеләү максатында башлангыч консультацияләр үткәрә.

Әйләнә тирә мохиткә йогынтыны алдан бәяләү барышында заказ бирүче түбәндәге мәгълүматны җыя һәм документлаштыра:

- ниятләнгән хуҗалык эшләре һәм башка эшчәнлек турында, аны гамәлгә ашыру максатын да кертеп, мөмкин булган альтернативалар, гамәлгә ашыру сроклары һәм күздә тотылган урнашу урыны, административ территорияләргә кагылышы,транспорт йорешенә киртәләр ясау мөмкинлеге, территориаль һәм тармак планнарына һәм программаларына туры килү турында;
- йогынтыга дучар ителергә мөмкин булган әйләнә-тирә мохит торышыһәм аның иң нык яклауга мохтаҗ компонентлары турында;
- әйләнә-тирә мохиткә карата булган иң зур йогынты (җир ресурсларына ихтыяҗ, көнкүреш калдыклары, транспорт һәм башка инфраструктураларга йөкләнеш, калдыкларны чыгару һәм ташлау) һәм бу йогынтыларны киметү яки булдырмау чаралары турында.

Йогынтыны алдан бәяләү нәтиҗәләре нигезендә заказ бирүче әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләүгә техник биремне (алга таба – ТБ) төзи, ул үз эченә түбәндәгеләрне ала:

- заказчының (башкаручының) исеме һәм адресы;
- әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләүне үткәрү сроклары;
- әйләнә-тирәлеккә йогынтыны бәяләүне уздыруның төп алымнары, шул исәптән җәмәгатьчелек белән консультацияләр үткәрү планы;
- әйләнә- тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләүдә төп бурычлар;
- әйләнә-тирәлеккә йогынтыны бәяләү буенча күздә тотылган материаллар составы һәм эчтәлеге.

ТБ төзегәндә заказ бирүче әйләнә-тирә мохитне саклау буенча махсус вәкаләтле органнарның таләпләрен, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү процессында башка катнашучыларның фикерләрен исәпкә ала.ТБ әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү процессында катнашучыларга аларның таләпләре буенча җибәрелә һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү үткәрү вакыты дәвамында җәмәгатьчелек өчен ачык була.

Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү өчен ТБ әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләү материалларының бер өлеше булып тора.
Заказ бирүче (башкаручы) әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча ТБ нигезендә тикшеренүләр үткәрә, тормышка ашыру альтернативасын, эшчәнлек максатларын, аларга ирешү ысулларын исәпкә алып һәм әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча материалларның якынча вариантын әзерли.

Әләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материаллары әзерләгәндә җәмәгатьчелекнең катнашуы түбәндәгечә гамәлгә ашырылырга мөмкин:

- беренче мәгълүмат тапшыру этабында;
- әйләнә-тирәлеккә йогынтыны бәяләү һәм нигезләү документларын әзерләү этабында.

Ниятләнгән инвестицион эшчәнлек өчен заказ бирүче әйләнә-тирәлеккә йогынтыны бәяләүнең барлык стадияләрендә дә дәүләт экологик экспертизасына тәкъдим ителә торган хуҗалык һәм башка төр эшчәнлек буенча документлар әзерләүнең югарыда аталган этапларын үткәрә.»;

1.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Җәмәгатьчелеккә әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материалларын алдан тәкъдим итү, танышу һәм искәрмәләрне тапшыру 30 көн эчендә, иҗтимагый фикер алышулар тәмамланганчы 2 атнадан да соңга калмыйча башкарыла.»;

2.5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.1. Заказчы:

- Алексеевск муниципаль районының рәсми басмаларында һәм район сайтында аларны үткәрүгә кадәр 30 календарь көннән дә ким булмаган вакыт эчендә җәмәгать фикер алышуларын үткәрү турында хәбәрнамәне (алга таба – басма материаллар)бастырып чыгаруны тәэмин итә.

Басмаларда түбәндәге мәгълүматлар күрсәтлә:

- ниятләнгән эшчәнлекнең исеме, максатлары һәм үткәрү урыны;
- заказчы яки аның вәкиленең исеме, адресы, телефоннары;
- әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауны бәяләүне уздыруның якынча сроклары;
- заказчының исеме, адресы, телефоны;
- иҗтимагый фикер алышуны оештыру өчен җаваплы орган;
- иҗтимагый фикер алышу формасы, шулай ук искәрмәләр һәм тәкъдимнәр тапшыру формасы;
- документларның ачык булу сроклары һәм урыны;
- башка мәгълүмат;»;

2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10.Ниятләнгән хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында Карар кабул итүгә кадәрге чорда гражданнар һәм иҗтимагый оешмалардан язма искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кабул итү,әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материаллары кушымталарында әлеге тәкъдимнәрне документлаштыру җәмәгать фикер алышуын үткәрүгә кадәр 5 календарь көн эчендә оештыручы тарафыннан тәэмин ителә һәм заказчы тарафыннан җәмәгать тикшерүе тәмамланганнан соң 30 көн эчендә тәэмин ителә.»;

Түбәндәге эчтәлекле 2.11 пунктын өстәргә:

«2.11.Әйләнә-тирәлеккә йогынтыны бәяләү буенча материалларның ахыргы варианты әйләнә-тирәлеккә йогынтыны бәяләү процессында катнашучылардан

кергән искәрмәләрне, тәкъдимнәрне һәм мәгълүматны исәпкә алып, материалларның беренчел варианты нигезендә әзерләнә. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча материалларның ахыргы вариантына кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу турында мәгълүмат, шулай ук җәмәгать тыңлаулары беркетмәләре кертелергә тиеш.

Әйләнә-тирәлеккә йогынтыны бәяләү буенча материалларның ахыргы варианты заказчы тарафыннан раслана, нигезләү документларын әзерләгәндә файдалану өчен тапшырыла һәм аның составында Дәүләт экологик экспертизасына тапшырыла.».

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Советының экология, җир мәсьәләләре, төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Муниципаль район башлыгы,**
**Совет рәисе** **С.А. Демидов**